СОВЕТ МАМАДЫШ-АКИЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ-ӘКИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**«02» июля 2025 года**

с.Мамадыш-Акилово

**КАРАР**
**№ 210**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» № 131 – ФЗ, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.:

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын паспортлаштыру.

2. Мамадыш-Әкил авыл җирлеге башкарма комитетына җирлекнең әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Мамадыш-Әкил авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Мамадыш-Әкил авылы, Ленин урамы, 50 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Татар Танае авылы, Үзәк урам, 1а йорт (авыл мәдәният йорты бинасы), Паново авылы, Үзәк урам, 26в йорт (авыл клубы бинасы).

**Мамадыш-Әкил Районы Башлыгы**
**авыл җирлеге, Совет рәисе** **Ф.Ф. Мирхәтуллин**